ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис, Верхнеуслонский район, Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Иннополис шәһәре

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының юл хәрәкәтен оештыру проектларын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14нче статьясы нигезендә, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995нче елның 10нчы декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законның 21нче статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007нче елның 8нче ноябреннән 257-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017нче елның 29нчы декабрендәге 443-ФЗ Федераль закон нигезендә, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының юл хәрәкәтен оештыру проектларын әлеге карарга кушымталар нигезендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Югары Ослан муниципаль районының (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырылган https://verhniy-uslon.tatarstan.ru/proekti-organizatsii-dozhnogo-dvizheniya.htm сылтамасы буенча расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет - телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Җитәкче Р. Р. Шагалиев